КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 15 сентябрь г.Казань № 1006

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының территориаль органы турындагы бертип нигезләмәне раслау хакында» 2006 ел, 3 апрель, 144 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының территориаль органы турындагы бертип нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының территориаль органы турындагы бертип нигезләмәне раслау хакында» 2006 ел, 3 апрель, 144 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 ел, 20 апрель, 193 нче; 2018 ел, 4 май, 320 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының территориаль органы турындагы бертип нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.2 пунктта «муниципаль районында (шәһәр округында)» сүзләреннән соң «, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге районнарында» сүзләрен өстәргә;

3.1 пунктта:

3.1.2 пунктчада «Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр реестрына кертелгән, әмма дәүләт йөкләмәсен (заказын) үтәүдә катнашмый торган социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан компенсация түләү тәртибен раслау һәм Татарстан

Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарлары үз көчен югалткан дип тану турында» сүзләрен «Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан компенсация түләү тәртибен раслау турында» сүзләренә алмаштырырга;

3.1.13 пунктча үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин